# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **27 ноябрь 2021 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Әгерҗе авыл җирлегенә керүче Мәнәвез
авылында 2022 елдаүзарасалым җыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегендә халык җыены карар бирә:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 (биш йөз) сум күләмендә, 1 төркем инвалидлар, укучыларның көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 80 яшьтән өлкән пенсионерлар өчен 400 сум күләмендә, алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:

- авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (Мәнәвез авылы урамнары исемнәре язылган күрсәткечләр, мәгълүмат стендлары сатып алу(әзерләү));
- спорт мәйданчыгы урнаштыру (мини футбол);
- күмү урыннарын карап тоту (агач кистерү, чүп-чар җыю һәм чыгару, кусторез сатып алу);
- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Корбан бәйрәме», «Яңа ел " бәйрәм чаралары, спорт чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү»):
- трактор йөртүчесенә хезмәте өчен түләү.

2. Әлеге халык җыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәнәвез авылы, Советская урамы, 1а адресы буенча, Мәнәвез авылы, Советская урамы, 29 йорт каршында, Мәнәвез авылы, Узәк урамы, 60 йорт каршында урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әгерҗе авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Хәсәнов

АЗНАКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
АГЕРЗИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1602002575
КПП 164301001